Тәрбияле бала җанга-шатлык, йөзгә аклык китерер.

# Хәерле иртә!

Иртән торып чыгуга
Урап алды чебиләр
Әй сөйлиләр, сөйлиләр:
-Чи –чи,чи- чи-чи...- диләр.
Казлар әйтә: Ка-га-га,
Ә үрдәкләр: Бак-бак-бак
Нәни бәбкәләре дә:
-Пип- пип, - диләр такмаклап
Берсен тотып иркәлим,
Икенчесен иркәлим...
Алар: “ пип- пип- пип”, - дисә,
Мин: “Хәерле иртә!”- дим.
Тукта, тукта! Нишләргә?
Әле төште хәтергә:
Әнигә бит шулай дип
Онытканмын әйтергә.

# Хәерле кич! Тыныч йокы!

Тәмле әйбер ашагач, авызга рәхәт була. Тәмле сүз ишеткәч, күңелгә рәхәт була. Ашый торгач, тәмле әйбер бетә. Ә тәмле сүз... Күпме генә тыңласаң да, күпме генә кабатласаң да, тәмле сүзнең кадере китми, рәхәте әйткән кешегә дә, ишеткән кешегә дә җитә. Безнең телебездә тәмле сүзләр бихисап! Төн узып, көн туу белән әйтелә торган сүз: “Хәерле иртә!”. Шуны бер отып алсагыз, өйдәгеләрне, күршеләрне, дусларны “Хәерле иртә!” дип сәләмләргә онытмысыз. Әле тагын”Хәерле көн!”,“Хәерле кич!” дигән сүзләребез бар.Көнне кешеләргә яхшылык, дөньяга иминлек теләп башладык. Ә нинди теләк белән тәмамлыбыз! Тыныч йокы теләп: “Тыныч йокы, әнием!”,”Тыныч йокы, әтием!”,”Тыныч йокы үземә, тыныч йокы күземә!”



# Исәнмесез!

Без, “Исәнмесез!” дип исәнләшәбез. Кайвакытта ахырдан кешенең исемен дә кушып әйтәбез: “Исәнмесез Зифа апа!”, “Исәнме Мансур!”- дибез. Яшьтәшләрнең, дусларның бер – берсенә “Сәлам!” дип эндәшүләре гаеп ителми.

- Өлкәннәр белән беренче булып сез – кечеләр исәнләшергә тиеш.
- Кызларны беренче булып малайлар сәламли.
- Бер үк кеше белән көненә берничә мәртәбә исәнләшмиләр.

Вакытка карап “Хәерле иртә!”, “Хәерле көн!”, “Хәерле кич!” дияргә була.

Күрдегезме инде, дөрес исәнләшә белү үзе бер һөнәр икән.Исәнләшә белеп тә, саубуллашырга оныта торган булсагыз,сезне барыбер тәрбияле бала димәсләр.

Саубуллашу сүзләребез берничә: “Хушыгыз!”, “Сау булыгыз!”, “Сау булып торыгыз!”



# Әдәплелек кагыйдәләре:

- Ашаганда сөйләшмә
- Табын янына беренче булып утырырга ашыкма
- Ризыкны авызыңны йомып чәйнә
- Кешене сөйләвеннән бүлдермә
- Кешегә бармагың белән төртеп күрсәтмә
- Мин сүзен еш кулланма, кабатлама
- “гафу итегез” димичә, кеше сүзенә кушылма
- Ишектән беренче чыгарга ашыкма.

# Табын янында

- Әти- әнидән алдан табын янына килеп утырма
- Табын янында борыныңны тартма, чөмереп ашама
- Аш алдыннан, аштан соң кулыңны ю
- Ипи валчыкларын коеп ашама
- Як- ягыңа карама, ризыксыз калырсың
- Чәеңне чөмереп эчмә
- Вакытында туя бел, кашыгыңны куя бел
- Ашка рәхмәт әйтә бел



# Рәхмәт!

“Рәхмәт!”, “Рәхмәт яусын!”,” Рәхмәтләр яусын!”.Бик тәмле сүзләр. Син аларның тәмен үзең дә беләсең, чөнки үзеңә генә аталганнарын гел-гел ишетеп торасың.Ә менә тиешле урында үзең дә рәхмәт әйтә бел. Әниең белән син килеп керүгә автобуста кемдер сикереп торып урын бирсә - “Рәхмәт!”диген.

